ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422700, ТР Биектау районы, Биектау тимер
юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

ГЛАВА КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
422700, Высокогорский район РТ,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская,13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**10 февраль 2016 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 431 статьясы, 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы закон, 2015 елның 3 нче ноябрнең 92-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле, муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы закон нигезендә, 2016 елның 3 нче февралендәге 21 нче номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башлыгының 2016 елның 3 февралендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый

актлары Регистрына кертү өчен җибәрү эше барышында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге регламентына таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

2. Җирлек советы, авыл җирлеге Башлыгы һәм җирлек Башкарма комитеты муниципаль норматив-хокукый актларны район Советына җибәрү, шулай ук регистрга кертелергә тиешле белешмәләр өчен авыл җирлеге башлыгы урынбасары Никитенко Р. Р. җаваплы итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасары Никитенко Р. Р. йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин